КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 6 март г.Казань № 212

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 28 июнь, 505 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 28 июнь, 505 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 01 сентябрь, 940 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктта «2018 - 2024» саннарын «2018 - 2025» саннарына алмаштырырга, «2014 - 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» сүзләрен «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

2.1 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмау. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Мөрәҗәгать итүче түбәндәге критерийларга туры килергә тиеш:

заявка биргән айның 1 числосына Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түли;

заявка биргән айның 1 числосына индустриаль (сәнәгать) парк территориясендә эшчәнлек башкару турында вәкаләтле орган белән гамәлдәге килешүгә ия;

сайлап алуны үткәрү елыннан алдагы елда электр энергиясе белән тәэмин итүче оешмага кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләүне гамәлгә ашырды һәм көчәнешнең түбәндәге диапазоннарының (дәрәҗәләренең) электр энергиясен кулланучы булды (кирәклесен ассызыкларга кирәк):

СН-I - көчәнешнең уртача беренче диапазоны (дәрәҗәсе) (алга таба - СН-I),

СН-II - көчәнешнең уртача икенче диапазоны (дәрәҗәсе) (алга таба - СН-II),

НН - көчәнешнең түбән диапазоны (дәрәҗәсе) (алга таба - НН).»;

3.1 пунктта:

дүртенче абзацка «сайлап алуны уздыру елына кадәрге елда» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацка «сайлап алуны уздыру елына кадәрге елда» сүзләрен өстәргә;

унынчы абзацка «индивидуаль эшкуарлар өчен» сүзләреннән соң «, юридик затларның, вәкаләтле затларның ышанычнамә буенча законлы вәкилләренең» сүзләрен өстәргә;

ундүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«салым органының заявка бирү аенының 1 числосына Федераль салым хезмәтенең «Салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча исәп-хисапларның торышы турында белешмә кәгазьләре формаларын, аларны тутыру тәртибен һәм белешмә кәгазьләрен электрон рәвештә бирү форматларын раслау хакында» 2021 елның 6 августындагы ЕД-7-19/728@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча исәп-хисаплары торышы турында белешмә кәгазе.»;

3.2 пунктның икенче абзацында «Салым түләүче (җыем түләүчесе, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты) тарафыннан салым, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар, аны тутыру тәртибе һәм аны электрон формада тәкъдим итү форматы турындагы белешмә формасын раслау турында» 2017 елның 20 гыйнварынндагы ММВ-7-8/20@ номерлы» сүзләрен «Салым түләүче (җыем түләүче, салым агенты) тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар һәм аны электрон рәвештә тапшыру форматы буенча белешмә формасын раслау турында» 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123@ номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктның дүртенче абзацында «30 нчы» сүзләрен «10 нчы» сүзләренә алмаштырырга;

5.1 пунктның өченче абзацында «субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләре» сүзләрен «субсидия бирү төгәлләнә торган төгәл дата һәм аны бирү нәтиҗәсенең соңгы күрсәткече (йомгакларның төгәл микъдари тасвирнамәсе)» сүзләренә алмаштырырга».

5.3 пунктның унөченче абзацында «куәтләре» сүзен «электр энергиясен тапшыру буенча хезмәт күрсәтүләргә тариф ставкасы буенча актив куәте» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 6 март, 212 нче
карары редакциясендә)

Форма

Гарантия хаты

___________________________________________________________________
(юридик затның исеме, шәхси эшкуарның Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

йөзендә ______________________________________________________________,
(вәкаләтле затның вазыйфасы, Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

____________________________________________________ нигезендә эш итүче
(индивидуаль эшмәкәрнең устав реквизитлары, төп дәүләт теркәү номеры таныклыгы,
___________________________________________________________________,
ышанычнамәсе)

гариза биргән айның 1 числосына түбәндәгеләрне гарантияли:

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмә булмау;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары, шулай ук Татарстан Республикасы каршында акча йөкләмәләре буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмау;

заявка бирүче юридик зат үзгәртеп оештыру (башка юридик затның заявка бирүчесенә кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәвын, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавын, ә сайлап алуда катнашучы индивидуаль эшкуар үз эшчәнлеген индивидуаль эшкуар буларак туктатмавын;

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор

компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмау. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 28 июнь, 505 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенең (алга таба - Тәртип) 1.1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акчалар алучы булмый;

кредит оешмасы, иминият оешмасы (кулланучылар кооперативларыннан тыш), инвестиция фонды, дәүләтнеке булмаган пенсия фонды, кыйммәтле кәгазьләр базарының профессиональ катнашучысы, ломбард булып тормый;

продукцияне бүлү турындагы килешүләрдә катнашмый;

уен бизнесы өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырмый;

Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләрендә каралган очраклардан тыш, валютаны җайга салу һәм валюта контроле турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе нерезиденты булып тормый;

эшчәнлекнең бер төре файдалы казылмаларны җитештерү һәм (яисә) сату, шулай ук чыгару һәм (яисә) сату, гомумтаралган файдалы казылмалардан тыш, файдалы казылмаларны җитештерү һәм (яисә) сату түгел, әгәр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан башкасы каралмаган булса;

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түли;

индустриаль (сәнәгать) парк территориясендә эшчәнлек башкару турында вәкаләтле орган белән гамәлдәге килешүгә ия;

сайлап алуны үткәрү елыннан алдагы елда электр энергиясе белән тәэмин итүче оешмага кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләүне гамәлгә ашырды һәм көчәнешнең түбәндәге диапазоннарының (дәрәҗәләренең) электр энергиясен кулланучы булды (кирәклесен ассызыкларга кирәк):

СН-I - көчәнешнең уртача беренче диапазоны (дәрәҗәсе),
СН-II - көчәнешнең уртача икенче диапазоны (дәрәҗәсе),
НН - көчәнешнең түбән диапазоны (дәрәҗәсе).

Җитәкче ________________ ____________________________________________
(имзасы) (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

М.У. (булганда)

20__ ел, «__» __________

___________________________